**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлегенең Кәрәкәс торак пунктында**
**2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

**14 ноябрь 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Кәрәкәс торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Кәрәкәс торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2025 елда үзара салымны 600 сум күләмендә билгеләргә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт эчендә агачларны һәм куакларны кисү);
- Россия Федерациясе халыкларының һәйкәлләрен (мәдәни мирас объектлары булмаган тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы һәйкәлендәге мемориаль тактаны алыштыру).

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә (Бигеш авыл җирлеге Уставының 69 ст. 5п.) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлеге башлыгы** ________________ **И.Р. Вәлиев**